**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Якты Күл авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30.11.2020 ел** **№ 14**

**Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы һәм бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты нигезендә, Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы һәм бурычны (алга таба - бурыч) түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- 3 елдан артык бурыч барлыкка килү датасы белән вафат булган физик затлар яисә Россия Федерациясенең граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгән затларның җир салымы һәм мөлкәткә салымы буенча;

- варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул ителмәгән очракта, вафат булган яки вафат булган дип игълан ителгән затларның җир салымы һәм мөлкәткә салымы буенча.

2. Карарны мәгълүмати стендларда, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Якты Күл авыл җирлеге башлыгы** **З. З. Мөхтәров**